


***Күәм урта гомуми белем мәктәбе газетасы*** *№3 Ноябрь 2023 ел*

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА
2023
УКЫТУЧЫЛАР һӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ



## Укытучы булып туган

Йомшак тавыш ишетелә: “Исәнмесез, ни хәлләрегез бар? Исән – имин генә барыгызда килеп җиттегезме?” Аның ягымлы йөзе генә дә , бу шау шулы мәктәп мохитенә канатланып кереп китәр өчен көч бирә. Сүзем кем турында дип уйлыйсыз? Әлбәттә, олы ихтирамга лаек, һәрберебезгә таныш булган, шат күңелле мөгалимә Хәкимҗанова Нурания Идерис кызы турында. Бәләкәй чагымда укытучы булуы бик җиңел дип уйлый идем. Үзем укытучы булгач аңладым: һәркемдә дә укытучы булырга сәләт юк. “Укытучы булып туарга кирәк “, ди халык. Хактыр. Күпме түземлек, сабырлык, тәртип, вакытны дөрес бүлә белү – тагын бик күп сыйфатларга ия булу кирәк. Нурания ханымда бу сыйфатларның барысы да бар.

1988 елда туган мәктәбемә эшкә килдем. Шул вакыттан бирле Нурания Идерис кызы белән бергә хезмәт итәбез. Ул хезмәттәш буларак, бик ярдәмчел. Анда масаю бөтенләй юк. Ничек итеп ярдәм кулы сузыйм, белмәгәнне өйрәтим, аңлатыйм икән дип борчылучы ул.

Балаларны ярату, гомерең буе аларга үрнәк булу, һәм дә алар белән дөрес аралашу – күпме ихтыяр көче таләп итә. Бар бала да Нурания апа янында бөтерелә, ярата, хөрмәт итә, ярдәм сорап килә. Ул һәр балага ярдәм кулы суза, игъибарсыз калдырмый. Аның укыткан укучылары да үзе кебек ягымлы, ихтирамлы.

Мин аңа сокланам. Ул белемле, күп эзләнүчән, барысыннан да хәбәрдар. Шуңа да Нурания Идерисовна район, республика, Россия күләмендә дәрәҗәле урыннарга лаек булган укытучы. Аның укучыларының уңышларын санап бетергесез. Хөкүмәтебез дә аның хезмәтен югары бәяли. “Мәгарифтәге казанышлары өчен” күкрәк билгесе иясе ул.

Нурания апа – оста бакчачы. Аның ишегалдына керсәң, гөлләр иленә кергән кебек буласың. Өлгер, уңган хуҗабикә. Бар җир тәртиптә, чисталык хөкем сөрә. Укучыларга да үз үрнәгендә белем һәм тәрбия бирергә тырыша. Гомумән, Нурания Идерис кызы – үрнәк укытучы, минә дигән хезмәттәш һәм сердәш, акыл бирүче, ярдәм итүче кеше.

Хөрмәтле Нурания Идерисовна, тагын күп елларны шушы мәктәп сукмагыннан атлап үтәргә язсын!

**Сөнгатова Гөлнара Зөлкарь кызы,**
**Татар теле һәм әдәбияты, тарих укытучысы**

## Бер тауда ун чишмә...

“Бер тауда ун чишмә, унысы ун төстә...” Сүзем ун чишмә турында бармаса да, әнә шул таудан аккан бер бик тә изге, гаять зур тарихлы чишмә хакында булыр. Сүзем, туган авылым - Күәм җирлеге территориясендә урнашкан "Изгеләр чишмәсе" хакында.


...Анда килеп керүгә гаҗәеп тынлык каршылый. Бигрәк тә җәен лепер - лепер килгән өрәңге яфраклары:

" Тавышланма, мондагы тынлыкны боза күрмә", - дия кебек. Изгеләр зираты бу. Ziратка кергәндә бик юан биек имән агачы үсеп утыра. Риваятьләргә караганда, монда изгеләр күмелгән. Шул исәптән, бер ханның биш кыз баласы да шушында дәфенләнгән диелгән. Алга таба урман эченнән атлап, нәкъ 159 баскыч түбән төшсәң, "Изгеләр чишмәсе"нә килеп чыгасың. Чишмәгә төшү юлы ныклы тимер баскычлардан эшләнгән. Әнә шул юл әкият иленә әйди кебек. Чишмә юлында үсеп утырган агачларга кунган кошлар да бүтәнчә сайрый монда, каядыр еракта күренгән кояш та бик серле ялтырый. Алдарак әйтелгән сихри тынлыкны бозып, ара-тирә кәккүк тавышы ишетелгәли.

Казан каласы беренче булып шушы тирәләрдә салына башлаган, диләр. Бәлки, чишмә юлының артык текә булуы, бәлки Ашыт елгасыннан ераграк булуы микән, халыкка монда төпләнергә комачау иткән. Ә чишмәнең суы нык салкын, саф сулы һәм шифалы да. Моннан бисмилла әйтеп эчкән су мең чиргә дәва, диләр өлкәннәр. Суы гына түгел,һавасы шифалы кебек.

Районыбызның гына түгел, барча Казан арты мөселманнарын берләштергән "Әләшә" бәйрәменең дә нәкъ менә шушы тирәдә, Кала тауда уткәрелүе дә тикмәгә түгелдер. Бу мөһтәмлык милли бәйрәм үтә торган урында илебезгә тынычлык, кырларга уңыш, якыннарыбызга исәнлек теләп дога кылына. "Изге чишмә" суы белән чәй кайнатып, халык коймак белән сыйлана. Киләчәктә дә “Изгеләр чишмәсе”нә эзләр суынмасын . Төбәк тарихыбыз бай, табигате матур, чишмәләре йөгерек, сулары шифалы. Бу матур урын бик күпләрне үзенә тартып тора. Чишмәләребез саекмасын, алар туган якның кабатланмас бизәге.

**Адель Баһавиев, 9 сыйныф укучысы**



"Хәрәкәттә - бәрәкәт" дип юкка гына әйтмиләр,бу дөрестән дә шулай. Тәнгә физик, актив хәрәкәт бик файдалы. Кич белән, безнең мәктәптә, волейбол тугәрәге уза. Ул дүшәмбе һәм чәршәмбе көнне сәгать кичке алтыда. Аны физкультура укытучысы Зарипов Булат абый алып бара. Вакытыгызны файдалы итеп уткәрәсегез килсә, кич белән волейбол уйнарга килегез.



## Кызыклы танышу

Без, 1 нче һәм 2 нче сыйныф укучылары, 17 нче ноябрь көнне Самат Шакир музеенда кунакта булдык. Самат абыйның тормышы, иҗаты белән безне Садриева Алия апабыз таныштырды. 2024 елда аңа 100 яшь була икән бит. Музейда без аның "Күәмнәрдә минем туган җирем "дип аталган җырын да тыңладык. Ә ахырдан музей җитәкчесе Алия апа, безгә Самат абыйның шигырьләрен укырга бирде. Мин әле аның шигырьләрен дә яттан өйрәнермен.

**Галявиев Ранил, 1 класс**

## Песикәем-пескәем.

Беркөнне мин урамнан кайтканда, кечкенә песи күрдем. Ул шундый кечкенә иде. Күзләре йомык, үзе бик хәлсез. Ул туңган иде.

Күптәннән минем песи алып кайтасы килә иде. Әни риза булмады. Әни эштә вакытта, мин ул песине өйгә алып кайттым. Юындырдым, ашаттым. Тартмага урын әзерләп, йоклаттым.

Эштән кайткач, әни мине ачуланды, әмма яңа дустымны куып чыгармады.

Песи тәрәзә төбендә утырып, урамны күзәтергә ярата. Тәрәзәдәге чебеннәрне дә куа. Аларны тотам дип, егылып та төшкәне бар. Кире тәрәзә төбенә менеп, чебен белән уенын дәвам итә. Гөлләрне дә читтә калдырмый.

Хәзер песи зур үсте. Кояш кебек сары төстә. Күзләре яшел. Көндез йоклый. Төн җиткәч уйный башлый. Аның яратып уйнаган уены, безнең бармакны кимерү. Ул шундый шук.

Мин песиемне бик яратам.

**Якупов Рәсим, 3 класс**

## Без - журналистлар

Без, 4 нче сыйныф укучылары барыбыз да "Мультимедийная журналистика» түгәрәгендә шөгыльләнәбез. Җитәкчебез - Сабирова Рита Рашатовна. Түгәрәк дистанцион рәвештә генә үтсә дә, без инде журналист һөнәренең серләренә өйрәнеп киләбез. Язган шигырьләребез, хикәяләребезне " В контакте" челтәрендә урнаштырып барабыз.

"Әтнә таңы" газетасы редакторы Гөлнар апа белән очрашу да үткәрдек.

## "Әтнә таңы"

"Әтнә таңы"газетасы
Киләдер һәрбер атна.
Бар яңалык,котлау сүзе,
Барысы да бар бит анда.

Языдыгыз һәм укыгыз,
Яхшы,әйбәт газета.
Кирәк дисәң язылырга,
Һәрвакытта да була.



**Миңлебаева Әлфинә, 4 класс**

## Әнидән кадерле кем бар?...



Җирдә миңа ни кирәк?
Әти дә әни кирәк!
Җирдә миңа ни кирәк?
Без яшәгән өй кирәк!

Минем әнием - Гөлия исемле. Аның исемедә җисеменә туры килә. Әнием - Арча районы кызы. Габдулла Тукай исемендәге совхоз техникумга 11 нче сыйныфны тәмамлап, укырга килә. Шунда әтием - Руслан белән таныша, Күәм авылында гаилә корып җибәрәләр.

Хәзерге көндә әнием Күәм авыл җирлегендә почтальон булып эшли. Авыл халкы әниемне гел көтеп ала,чөнки ул хатлар, яңалыклар тулы сумкасын асып, аларга җылы караш күрсәтеп, тәмле сүзләрен әйтеп хезмәт күрсәтә.

Минем әнием өч бала әнисе,оста пешекче, ул минем "повар-кондитер", шуның өстенә бик моңлы җырчыда әле. Әлеге вакытта "Әтнә сандугачы" бәйгесендә чыгыш ясап килә. Әнием безне гел тәмле ризыклары,татлы сүзләре, җылы карашы, йомшак куллары белән каршы ала. Һәрвакыт ул безгә хәер-фатихасын бирә. Без әниебезне бик нык яратабыз!

**Хәбибуллина Әдилә, 8 класс**

## Кыш

Буранлы салкын кышлар да килде,
Бөтен дөньяны ак карга күмде.
Елгаларда сулар бозланды,
Басулар ак юрган ябынды.

**Юсупова Динә, 2 класс**

## Халык сынамышлары

- Ноябрь, бүгенге суык киләсе ел мул уңышына ишарә. Көн җылы булса, кыш җылы килер.
- Ноябрь, иртәдән бәс - карлы кышка ишарә.
- 28 ноябрь көнне яткан кар язга кадәр эреми.
- Ноябрь ахырында көн кояшлы икән, кыш кояш белән әллә ни сөендермәс, көн суык булса, суык өлешсез калдырмас.

## Илләр һәм континентлар

- Төньяк ярымшарда салкынлык полюсы дип аталу хокукы өчен Якутиядәге ике торак пункт "көрәшә": Оймякон һәм Верхоянск. 1933 елның февралендә бу поселокларда температураның – 67,7 С һәм – 67,8 С булуы теркәлгән.
- Д.Артаньян – һәйкәл куелуга лаек булган аз санлы әдәби геройларның берсе. Мушкетёрның туган җире – Ош шәһәрчегендә, Парижда ( Дюмага куелган һәйкәлнең бер өлеше) һәм камалуда калган мушкетёр һәлак булган Маастрихт (Голландия) шәһәрендә аңа һәйкәлләр бар.
- Иң куркыныч һәлакәт 79 елда Визувей атылганда була: бай һәм чәчәк атып утырган өч шәһәр һәлак була. Помпей вулкан көле ( калынлыгы 8 м га кадәр) белән каплана, Стабия лава, ә Геркуланум пычрак белән тула.